**УКАЗ**
**ПРЕЗИДЕНТА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ПРЕЗИДЕНТЫ**
**УКАЗЫ**

## Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 пункты нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2013 ел, 24 май
№ ПУ-444

Татарстан Республикасы
Президентының
2013 елның « 24 » маендагы
ПУ- 444номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә түләүсез юридик ярдәм турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 324-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә түләүсез юридик ярдәмгә хокуклары булган гражданнарга аны күрсәткәндә Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт түләүсез юридик ярдәм системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге механизмын билгели (алга таба тиешенчә – дәүләт системасы, гражданнар).

2. Татарстан Республикасы Законының 9 статьясы нигезендә дәүләт системасында катнашучылар түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм алар карамагындагы учреждениеләр;

законнар нигезендә дәүләт бюджеттан тыш фондларының идарә органнары.

Адвокатлар Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Законында каралган тәртиптә дәүләт системасында катнашалар.

3. Дәүләт системасында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге формалары түбәндәгеләр:

1) гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне тәэмин итү белән бәйле мәсьәләләр буенча уртак чараларны планлаштыру һәм гамәлгә ашыру;

2) гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында хисаплар бирү;

3) законнар нигезендә ведомстволар арасында мәгълүмати хезмәттәшлек;

4) законнар нигезендә үзара хезмәттәшлекнең башка формаларын гамәлгә ашыру.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары карамагындагы учреждениеләр, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, квартал саен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең тиешле органнарына Татарстан Республикасы

территориясендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында Татарстан Республикасының гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү һәм кыен тормыш хәленә дучар булган гражданнарга ашыгыч очракларда түләүсез юридик ярдәм күрсәтү өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы (алга таба – вәкаләтле орган) раслый торган форма буенча хисаплар җибәрәләр.

5. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары (алар карамагындагы учреждениеләр тарафыннан тапшырылган күрсәткечләрне исәпкә алып), дәүләт бюджеттан тыш фондларының идарә органнары, хисап кварталыннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, вәкаләтле орган тарафыннан раслана торган форма буенча квартал саен Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында хисаплар җибәрәләр.

6. Вәкаләтле орган, хисап кварталыннан соң килүче айның 20 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының һәм дәүләт бюджеттан тыш фондлары идарә органнарының һәр квартал саен бирелә торган хисаплары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында һәр квартал саен җыелма хисаплар әзерли һәм аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтына урнаштыра.

7. Әлеге квартал саен бирелә торган җыелма хисаплар һәм «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы» дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешманың (алга таба – Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы) адвокатлар тарафыннан дәүләт системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турындагы җыелма хисабы нигезендә вәкаләтле орган ел саен, 28 февральдән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында еллык җыелма хисап әзерли һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтына урнаштыра.

8. Вәкаләтле орган ел саен, 1 декабрьдән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы белән гражданнарны түләүсез юридик ярдәм белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы (алга таба – вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы) тарафыннан раслана торган форма буенча дәүләт системасында катнашучы адвокатлар тарафыннан гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи.

9. Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы ел саен, 15 ноябрьдән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга, дәүләт системасында катнашучы адвокатларның аларның Татарстан Республикасы адвокатлары реестрында теркәлү номерлары күрсәтелгән исемлеген, шулай ук адвокатлар үзләренең профессиональ эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган адвокатлар оешмалары исемлеген (алга таба – адвокатлар исемлеге) җибәрә.

10. Вәкаләтле орган ел саен, 31 декабрьдән дә соңга калмыйча, массакүләм мәгълүмат чараларында адвокатлар исемлеген бастырып чыгара һәм шушы исемлекне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.

11. Хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, вәкаләтле орган квартал саен Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасыннан адвокатлар исемлеге үзгәрү турында мәгълүмат соратып ала.

Вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасыннан шушы мәгълүматны алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган адвокатлар исемлегенә тиешле үзгәрешләрне кертә.

12. Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы, дәүләт системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында Федераль законның 18 статьясындагы 7 өлеше нигезендә адвокатлар тарафыннан тапшырыла торган хисапларны исәпкә алып, 20 февральдән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга дәүләт системасы кысаларында адвокатлар тарафыннан түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы раслаган форма буенча еллык доклад һәм җыелма хисап җибәрә.

13. Дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләгәндә һәм аларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләгәндә вәкаләтле орган белән Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы арасындагы хезмәттәшлек тәртибе Килешү белән һәм дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм аларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган тәртип белән билгеләнә.

14. Гражданга дәүләт системасы кысаларында түләүсез юридик ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы Законының 13 статьясында каралганча бирелә торган документлар нигезендә гариза бирү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

15. Граждан (аның законлы вәкиле) тарафыннан куелган мәсьәләләрне хәл итү дәүләт системасында бүтән катнашучы компетенциясенә кергән очракта, граждан шәхси рәвештә мөрәҗәгать иткәндә, аңа мөрәҗәгать иткән көнне мөрәҗәгать итү тәртибе аңлатыла. Гражданнан (аның законлы вәкиленнән) түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сораган язмача мөрәҗәгать алынганда, гражданның мөрәҗәгате эш көннәре белән исәпләгәндә 2 көн эчендә тиешле дәүләт системасында катнашучыга җибәрелә.